ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенең, шулай ук, әгәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторлары вазыйфалары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарының һәм аудиторларының» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенең, рәисе урынбасарының һәм аудиторларының» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 6 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 статьяның $2^1$ өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 1 нче кушымтада:
а) 3 бүлекнең 2 пунктындагы өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) 7 бүлекнең 2 пунктындагы алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2 нче кушымтаның 6 пунктындагы ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 март
№ 10-ТРЗ